ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**«24» декабрь 2021 ел** **№ 22**

**Арча муниципаль районы «Үрнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Үрнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы составына керә торган торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Үрнәк авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 октябрендәге 30 номерлы карары нигезендә 2021 елның 08 ноябрендәге № 1, 2021 елның 09 ноябрендәге № 2, 2021 елның 10 ноябрендәге № 3, 2021 елның 11 ноябрендәге № 4, 2021 елның 12 ноябрендәге №5, 2021 елның 12 ноябрендәге № 6, 2021 елның 12 ноябрендәге № 7, 2021 елның 15 ноябрендәге №8, 2021 елның 16 ноябрендәге №9, 2021 елның 16 ноябрендәге №10, 2021 елның 16 ноябрендәге №11, 2021 елның 17 ноябрендәге №12, 2021 елның 17 ноябрендәге №13, 2021 елның 18 ноябрендәге №14, 2021 елның 18 ноябрендәге №15 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Үрнәк авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча муниципаль районы «Үрнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм Ашытбаш авылы, Г.Тукай урамы, 19 нчы йорт, Иске Ашыт авылы, Мәктәп урамы, 4 нче йорт, Үрнәк авылы, Ленин урамы, 53 йорт адреслары буенча гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Үрнәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 нчы елның 18 декабрендә чыккан 19 нче номерлы «Үрнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков

Үрнәк авыл җирлеге
Башкарма комитетының
24 декабрь 2021 ел, №
22 карарына
1 нче кушымта

**Арча муниципаль районы «Үрнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Арча муниципаль районы «Үрнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә күрсәткән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2022 елның 18 февраленә кадәр муниципаль берәмлек территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Аерым категория гражданнар өчен:

а) көндезге формада белем алучы студентлар

б) 1 нче төркем инвалидлар

в) Бөек Ватан сугышы ветераннары өчен

түләү күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-ана, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсенә зыян килү,

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан да артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

5. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр (хәбәрнамә) бланкы гражданнар игътибарына (http://pravo.tatarstan.ru) сайтында басылып чыгу юлы белән хәбәр ителә һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында ( http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмати стендларда, шулай ук кул куйдырып үзенә тапшыру яисә почта аша җибәрү юлы белән халыкка җиткерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар «Үрнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла, «Үрнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты кассасы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша сылтама https://uslugi.tatarstan.ru/ буенча башкарыла.

8. Түләүне дәлилли торган документ булып керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Үрнәк авыл җирлеге
Башкарма комитетының
24 декабрь 2021 ел,
№22 карарына
2 нче кушымта

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________

«Үрнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләү турында

Түләүченең ф. и.
а.и.________________________________________________________
Адресы:_____________________________________________________________
____________________________________________________________нигезендә
Сезгә __________ кадәр ________ сум күләмендә
___________________________________чаралар гамәлгә ашыру өчен
түбәндәге реквизитлар буенча:
БИК банк __________________________
Сч. № ______________________________________
Счетны алучы. № ______________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _________________ОКАТО__________________
Түләү билгеләнеше ____________________________________________________бер
тапкыр түләү түләргә кирәк.

Җитәкче _________________ ________________________________________
М. у. (имза) ( имзаны аңлату)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

«Үрнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына __ сум күләмендә бер мәртәбә түләнә торган үзара салым түләү буенча хәбәр (хәбәрнамә) № ___
Түләүченең ф. и. а.и.___________________________________________
Адресы: _______________________________________________
Алдым «___» _______________ 20__ ел _____________________________________
(имза/түләүченең ф.и.а.и.)

*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, өзмә корешок тутырыла һәм ул Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*